**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Первомайская ул., д.39, г. Лаишево, 422610
Тел: 8 (84378) 2-51-51
Факс: 8 (84378) 2-55-55
e-mail: Sovet.Laishevo@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

Беренче май ур., 39 нчы йорт, Лаеш ш., 422610
Тел: 8 (84378) 2-51-51
Факс: 8 (84378) 2-55-55
e-mail: Sovet.Laishevo@tatar.ru

---

**2025 елның 13 нче ноябрь** **номер 16-РС**

# КАРАР

**«Лаеш муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы турында нигезләмәне раслау хакында» 2005 елның 22 декабрендәге 35 номерлы Лаеш муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Җир кодексының 11.10 һәм 39.15 статьяларына һәм «Геодезия, картография һәм пространство мәгълүматлары турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 18.1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Пространство күрсәткечләренең милли системасы» федераль дәүләт географик мәгълүмат системасы турында» 2022 елның 07 июнендәге 1040 номерлы карары, «Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставы белән, Лаеш муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ**:

1. «Лаеш муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы турында нигезләмәне раслау хакында» 2025 елның 22 декабрендәге 35 номерлы Лаеш муниципаль районы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1түбәндәге эчтәлекле 3.41 пункт өстәргә.:

«3.41. Үз вәкаләтләрен тәэмин итү өчен Палата дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системаларын, шулай ук пространство белешмәләренең милли системасы эшләвен тәэмин итә торган федераль дәүләт Географик мәгълүмат системасын файдаланырга хокуклы.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының http:/laishevo.tatarstan.ru. рәсми сайтында урнаштырырга. һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

**Муниципаль район Советы**
**рәисе-башлык вазифаларын башкаручы** **Т.П. Борһанова**